«Рассмотрено»
Руководитель МО

Хузина Р.Т.
Протокол № 1
от «23» 08 2017 г.

«Согласовано»
Заместитель директора по УРВ ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»
Яковлева М.В.
от «23» 08 2017 г.

«Утверждаю»
Директор
ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»
Беспалова Т.В.
Приказ № 43
от «25» 08 2017 г.

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

учебного предмета, курса, дисциплины (модуля)
ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»

Хузина Розалия Талгатовна, высшая категория
Ф.И.О., категория

по татарскому языку, 9А класса
предмет, класс и т.п.

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол № 43
от « 23» 08 2017 г.

20 17 - 20 18 учебный год

# УЧЕБНО-ТЕМАТИЧЕСКОЕ ПЛАНИРОВАНИЕ ПРАКТИЧЕСКОЙ ЧАСТИ УЧЕБНОЙ ПРОГРАММЫ ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ

Класс: 9А
Учитель: Хузина Р.Т.
Количество часов: всего - 68;  в неделю – 2.
Плановых контрольных работ: 4
Административных контрольных работ: 2

9 сыйныфның рус төркемнәрендә укучылар өчен татар теленнән

**эш программасы**

Укытучы Хуҗина Рузилә Тәлгать кызы

**Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләренең рус төркемендәге 9 нчы сыйныф укучылары өчен татар теле буенча белем бирү программасына аңлатма язуы**

**1. 9 нчы сыйныф өчен эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:**

- Россия Федерациясе мәгарифе турында»гы федераль закон *( 2012 нче елның 29 нчы декабрендә Россия Федерациясе Президенты тарафыннан имзаланган 273 нче ФЗ; 2013 нче елның 1нче сентябреннән гамәлдә);*
- «ТР дәүләт телләре һәм ТРсындагы башка телләр турында»гы Татарстан Республикасы законы;
- «Мәгариф турында» гы Татарстан Республикасы законы (№ 68, 2013 нче елның 22 нче июле);
- «2014-2020 нче елларда ТР сы дәүләт телләрен һәм ТРның башка халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» ТРсы дәүләт программасы (ТР Министрлар Кабинетының 2013 нче елның 25 нче октябреннән 794 нче карары)
- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән "Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы" (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) 1-11 нче сыйныфлар өчен, К.С.Фәтхуллова, Ф.Х.Җәүһәрова, - Казан; Мәгариф; 2013
- Лицейның белем бирү программасы.
- "Н.Лобачевский исемендәге Академик лицей" ның укыту планы.
- "Н.Лобачевский исемендәге Академик лицей" ның "Эш программалары" буенча локаль акты

Программа татар телен өйрәнү өчен гомуми белем бирү уку предметы буенча Дәүләт стандартының федераль компонентның эчтәлеген ачыклый.

**Укыту фәненең уку планында токтан урыны программада күрсәтелгәнчә: елга барысы – 68 сәг., атнага – 2 сәг.**

**Арадаш аттестация үткәрү формасы: Бердәм Республика тесты**

**2. Укыту предметының бурычлары һәм максатлары:**

Рус телле балаларга татар теле укыту **максатлары** берничә юнәлешне үз эченә ала: **танып белү, үстерү, тәрбияви, белем бирү**

юнәлешләре.

**Танып белү максатының эчтәлеге**

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып торган татар халкы мәдәнияте, гореф-гадәтләре, тарихи үткәне, бүгенгесе турында хәбәрдар булу, киләчәген күзаллау зарур. Татар халкы белән үзара тыгыз элемтәдә яшәүче башка милләт кешеләре татарларның милли бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият- сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзен рухи яктан баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш, дип саныйбыз. Дәреслек эчтәлеге телгә өйрәтү процессын бала өчен «башка дөньяга тәрәзә ачу» (И.Л.Бим) булырлык һәм шуның аркылы үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайланды.

Программа материалын өйрәнү барышында укучыларның Татарстан Республикасында яшәүче милләтләр, Татарстанның дәүләт символлары, республиканың территориясе, географик урыны; башкалабыз Казанның тарихи үткәне, бүгенге йөзе; татар сәнгатенең төрле тармаклары, күренекле шәхесләр турында билгеле бер мәгълүмат алуы максат итеп куела.

**Үстерү максатының эчтәлеге**

Шәхеснең белемле булуы аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында **үстерү максатларын** даими күзаллап эшләү — укытуның гамәли яктан уңышлылыгының алшарты.

Балаларның психик яктан камилләшүен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар бирү таләп ителә:

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү;
- хәтерне *(ихтыярый, ихтыярсыз),* игътибарлылыкны үстерү;

*аралаша белү сәләтен үстерү* (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре*);*

**Тәрбияви максатның эчтәлеге**

Тәрбиянең нәтиҗәлелеге, беренче чиратта, укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алу мөһим. Татар теле

грамматикасын өйрәнү барышында әхлакый проблемаларны чагылдырган текстлар белән эшләү, ул текстларны лексик-грамматик яктан анализлау белән генә чикләнмичә, текстта күтәрелгән проблема буенча укучыларның үзара фикерләшә, аралаша белүләрен оештыру бик мөһим. Әхлакый проблеманы чагылдырган текстларның эчтәлеге үзе үк коммуникатив мотивациягә ия, шунлыктан дәрестә аралашу ситуациясе булдыру әллә ни кыенлык тудырмый.

**Белем бирү максатының эчтәлеге**

Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр җыелмасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык югарылыкка җитүе зарур. Ягъни укучы, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатыннан мөстәкыйль кулланырлык итеп өйрәнергә тиеш. Шул вакытта гына татар телен аралашу чарасы буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

**Үзләштерелергә тиешле грамматик минимум**

- Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләренең исемнәрен әйтә, аларга сорау куя,аера белү.
- Гади һәм кушма җөмләләрне аера белергә өйрәтү.
- Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрне сөйләмдә куллана белү күнекмәләрен булдыру.
- Җыючы, каршы куючы, бүлүче теркәгечле кушма җөмләләрне сөйләмдә куллану.
- Иярчен хәл җөмләләрнең **иярчен урын җөмлә, вакыт җөмлә, сәбәп җөмлә, максат җөмлә, шарт җөмлә, кире җөмләләре** белән таныштыру һәм ал арны сөйләмдә урынлы кулланылуына ирешү.
- Тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес куя һәм аларны тиешле интонация белән әйтә белү.

Укыту процессының уңышлылыгына тәэсир итә торган әһәмиятле факторларның берсе — ул укучыларның белемен **контрольгә** алу. Билгеле булганча, контроль — укыту барышын көйли, ягъни, контрольгә карап, укытучы үз эшчәнлеген оештыра. Методика фәне билгеләгәнчә, **контроль объекты** булып укучыларның аерым сүзләрне, җөмләләрне тәрҗемә итә белүләре, яисә грамматик категорияләрне аңлый алулары гына була алмый. Контрольнең төп объекты булып, укучының өйрәнелгән лексиканы һәм грамматиканы кулланып, **мөстәкыйль аралаша алуы**

тора. Календарь-тематик планның коммуникатив максат графасында күрсәтелгән **предмет нәтиҗәләре** балаларның белем дәрәҗәсенең, ягъни **татарча сөйләшеп аралаша алу** күрсәткече булып тора.

Методик ярдәмлектә **аудирование** *(ишетеп аңлау күнегүләре)* тәкъдим ителә. Бу күнегүләр һәр дәрестә, дәреснең төрле этапларында да кулланыла ала. Ишетеп аңлау күнегүләренә таләпләр кечерәк сыйныфлар өчен чыгарылган ярдәмлекләрдә киң яктыртылу сәбәпле, күнегүләрнең үзләрен бирү белән генә чикләндек.

Дәреслектә киң урын алган күнегү төрләренең берсе — **ситуатив күнегүләр.** Бу күнегүләр коммуникатив технологиягә корылган дәресләрнең төп максатын тәшкил итә, чөнки нәкъ менә ситуа-

тив күнегүләр балаларны тормышта аралашуга әзерли. Дәресләрнең күләме чикле булу сәбәпле, эшләргә мөмкин булган барлык ситуатив күнегүләр дә дәреслектә урын алмады. Укытучылар ярдәмгә шул ук авторлар төзегән *(Хайдарова Р.З., Гиниятуллина ЛА.Сборник ситуативных упражнений по татарскому языку для русскоязычных учащихся. — Наб.Челны, 2004)* дидактик материалга мөрәҗәгать итә алалар. Бу күнегүләр укучыларга таратма материал буларак та кулланыла ала.

Уку эшчәнлеген оештыруда парларда, төркемнәрдә эш төрләре дә аеруча әһәмиятле булып тора.

## 3.Программа материалының эчтәлеге

Тематик эчтәлек:
-Без Татарстанда яшибез
-Һөнәр сайлау
-Сәламәтлек **— зур** байлык
-Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый

-Моннан тыш, алдагы сыйныфларда өйрәнелгән лексик-грамматик материалны даими рәвештә кабатлап бару укытучының укыту-методик бурычы булып тора.

## 4.Укыту предметы буенча укучыларның белем, күнекмә һәм эшчәнлек алымнары.

Гомуми белем мәктәбендә татар теле дәресләре укучыларның сөйләм телен үстерүгә юнәлтелә, бу исә аларның **тыңлап аңлау, сөйләү һәм сөйләшү, уку, язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен формалаштыруны** үз эченә ала.

**Тыңлап аңлау.**

- Өч минутлык текстны тыңлап, аның эчтәлеге буенча әңгәмә кору;
- диктор сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләренә ия булу.

**Диалогик һәм монологик сөйләм.**

- Укылган (тыңланган) текстның эчтәлеге буенча фикер алышуда катнашу;
- кара-каршы сөйләшү барышында аралашу максатына ирешә һәм үз фикереңне дәлилли алу; тәкъдим ителгән ситуация буенча
сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны уннан ким булмаска тиеш);
- сәяси-иҗтимагый вакыйгалар һәм мәдәният яңалыклары турында хәбәр итү (җөмләләр саны уннан ким булмаска тиеш);
- табигать күренешләрен, кешеләрне тасвирлый белү; укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген эзлекле сөйләп бирү.

**Уку.**

- Фәнни-популяр стильдәге текстларны, диалогларны тиешле темпта уку,эчтәлеген аңлау һәм сөйли алу;
- шигырьләрне сәнгатьле итеп уку, яттан өйрәнү күнекмәләренә ия булу.

**Язу.**

- Лексик темага караган бәйләнешле текст язу;
- укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген киңәйтеп яки кыскартып,язмача белдерә алу;
- рәсми кәгазьләрне (ышаныч язуы,аңлатма язуы) үрнәк буенча тутыра белү;
- котлау (чакыру) хатлары,белдерү яза алу.

Лексик темага караган бәйләнешле текст язу; укылган текстның эчтәлегенязу, бирелгән үрнәк буенча рәсми кәгазьләрне, хатларны язу.

Язма эшнең күләме:

Диктантлар - (65-80 сүз) Изложение – ( 110 -130 сүз)

**Контроль төрләре**

1. Өй эшләрен даими тикшереп бару
2. Укучыларның мөстәкыйль эшләүләрен булдыру һәм аны башкаруны контрольдә тоту.

3. Темалар буенча тест биремнәрен башкару
4. Чирек ахырында һәм сыйныфара аттестация биремнәрен үтәү.

**Таләп ителгән нәтиҗәләргә ирешү өчен кулланыла торган педагогик технологияләр:**

- коммуникатив технологияләр нигезендә укыту принципларын куллану;
- телне аралашу аша өйрәнү;
- укыту процессын индивидуальләштерү;
- телне актив фикерләү нигезендә өйрәнү;
- телне функциональ өйрәнү.

**9 сыйныфта татар теленнән үзләштерелергә һәм камилләштерелергә тиешле гомумкүнекмәләр**

***Уку эшчәнлеген оештыра белү юнәлешендә***

1. Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.
2. Эшне планлаштыра белү.
3. Эшнең дөреслеген тикшерү.
4. Авазларны сүзләрдә, сүзтезмәләрдә, җөмләләрдә дөрес әйтүгә ирешү һәм сингармонизм законының асылына төшенү;
5. Сөйләмне орфоэпик һәм орфографик яктан дөрес оештыра белү;
6. Исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш кебек мөстәкыйль сүз төркемнәре турында мәгълүматлы булу;

***Китап, өстәмә мәгълүмат белән эш итү***

1. Дәреслек белән эш итә белү.
2. Төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эш итә белү.
3. Төрле текстлар белән эш итү.
4. Белемнәрне системалаштыру өчен таблица, график , схемалардан файдалану.
5. Эчтәлекне аңлап, тиешле тизлектә, дөрес уку.
6. Китапханәдә каталог белән эш итә белү.
7. Аудио-видео белән эш итә белү.

***Фикерләү белән бәйле күнекмәләр***

1. Уку мәсьәләсен куя белү.
2. Яңа теманы аңлауга мотив тудыру.
3. Танып белү активлыгын үстерү.
4. Төшенчә, термин,кагыйдә,закончалыкларны аңлап кабул итүкүнекмәләрен камилләштерү.
6. Тикшеренү ысуллары:
7 . Татар һәм рус телләрендә уртак булган, ләкин әйтелешләре белән аерылган авазлы сүзләрне дөрес әйтә белү;

***Телдән һәм язма сөйләм үстерү һәм аралаша белү юнәлеше***

**Телдән сөйләм:**

1.Сорауны формалаштыра белү һәм тулы җавап бирә белү күнекмәсе;
2.Татар телендә җөмлә төзелеше, җөмлә кисәкләре турында төшенчәне үзләштерү һәм куллана белү;
3.Коммуникатив максатларны аңлап, диалогик аралашуда катнашу;
4.Төрле аралашу сфераларыннан чыгып,телдән яки язмача үз фикереңне белдерүгә ирешү;
5.Тәрҗемә итү күнекмәсе.
6.Тиешле күләмендә татар сүзләрен яттан белү.

**Язма сөйләм**

1. Күчереп язу;
2. Фикер йөртү элементлары кертеп, әзер план буенча бирелгән диалог, монолог язу
3. Изложение язу
4. Тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле монологик сөйләм төзи алу;
7.Уку елы ахырында- 80-90 сүз;
8. Сүзлекләрдән файдалана белү.

**Укытуның предмет, шәхси, метапредмет нәтиҗәләре**

Федераль дәүләт белем стандартларында белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше — **системалы-эшчәнлекле юнәлеш,** ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент — **нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре** дип билгеләнелә. Стандартлардакүрсәтелгән бу концептуаль методологик нигез барлык фәннәрне укыту системасына да, шул исәптән рус телле балаларга татар теле укыту системасына да карый. Ягъни рус телле балаларга

татар теле укыту системасының барлык компонентлары да: программалар, укыту-мето- дик комплектлар, дәрес барышы, контроль, идарә итү, белем күтәрү һ.б. — бар да бер максатка — **нәтиҗәгә** хезмәт итә.

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньяда тоткан мөһим урыны турында күзаллау формалаша. Татар мәдәниятенең аерым үрнәкләре белән танышу рус телле укучыларда башка мәдәнияткә карата ихтирам хисе уята һәм укучыларга үз халкының мәдәниятен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

**Укытуның предмет нәтиҗәләре**

Төп гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаганда, рус телле укучылар татар теленнән түбәндәге предмет нәтиҗәләренә ия булырга тиеш:

-коммуникатив компетенциягә (аралашу осталыгына) ия булу, ягъни татар телендә телдән яки язмача аралашу күнекмәләрен үзләштерү;

- коммуникатив бурычлар куя һәм аларны хәл итә белү; аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итәгатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;

- «Татар теле» фәнен өйрәнүгә карата уңай омтылышта булу, татар теле белән даими кызыксыну һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштерү.

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре**

Төп гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаганда, укучының үзенә һәм әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре** формалашкан булуы күзаллана:

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караштa булу һәм аны яхшы өйрәнү теләгенә ия булу;

- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;

- текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирә белү;

-*гаилә, туган ил, туган җир, мәрхәмәтлелек* төшенчәләрен аңлап кабул итү; укучыда башкаларга карата түземлелек, кайгырту- чанлык, кеше кадерен белү кебек хисләр формалашу.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Төп гомуми белем бирү баскычында укучыларда киң мәгълүматлы җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерү буенча эш дәвам иттерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр; хәрәкәтле, яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмат чаралары белән эшләү тәҗрибәсен ныгыта; презентация материаллары әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясау күнекмәләрен үстерә; укучыларда, компьютер яисә мәгълүмати-коммуникатив технологияләрнең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре камилләшә.

Бу чорда татар телен укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук чынбарлыкта килеп туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган **универсаль** (*танып белү, регулятив, коммуникатив)***уку гамәлләрен** формалаштыруны дәвам итә.

Төп гомуми белем бирү баскычында укучыларның түбәндәге **универсаль уку гамәлләренә** ия булуы күзаллана.

Танып белү универсаль уку гамәлләре:

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне табу;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
- тиешле мәгълүматны табу өчен энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләренә ия булу;
- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
— укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый һәм, кирәк булганда, төзәтмәләр

кертә белү;

- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сыйфатларга ия булуга ирешү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңлый һәм аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзи белү;
- ***аралаша белү сәләтләрен формалаштыру*** (аралашучанлык, хиселелек, эмпатия хисләре),
-парлап һәм төркемдә эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

5. **<u>Материаль-техник яктан тәэмин ителеш.</u>**

1.Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыклары тарафыннан тәкъдим ителгән“Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы” (1-11нче сыйныфлар),төзүче-авторлары: Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева, Казан, 2011;

**2.**. Диск “Татар теле 5-11 “-Казан: “Белем. ру.”, - 2009

**Укыту методик комплекты:**

1. Дәреслек:Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыклары тарафыннан тәкъдим ителгән: Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек( татар телен өйрәнүче укучылар өчен). Казан. “Татармультфильм” нәшрияты. Автор: Р.З. Хәйдарова, Г.И.Ибраһимова, Р.Л.Малафеева,2015.

2. “Рус телендә урта (тулы ) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен үрнәк программалар. 2011нче ел Татарстан китап нәшрияты, 2011. Төзүче-авторлары: Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева.

**Өстәмә әдәбият**

1.Нигъмәтуллина Р.Р.Татар теле өйрәнүчеләргә кагыйдәләр һәм күнегүләр.- Казан: Мәгариф
2. Гыймадиева Н. Контроль диктантлар һәм изложенияләр./Н.Гыймадиева, Р.Бахавиева.- Казан: Яңалиф, 2004.-96 б.
3. Нигъмәтуллина Р.Р. Татар теле өйрәнүчеләргә кагыйдәләр һәм күнегүләр. /Р.Р.Нигмәтуллина.- Казан: Магариф, 2004.-205 б.
4. Р.Н.Фатыйхова. Татар теленнәндиктантлар, контроль эшләр,тестлар. – Казан, “Гыйлем” нәшрияты, 2009.

5. Насибуллина Р.Н. “Татарский язык в таблицах и схемах для русскоязычных учащихся начальных классов”. - “Мәгариф”нәшрияты,2007.
6. “Фән һәм мәктәп”, “Мәгариф” журналлары, “Мәгърифәт”, “Ачык дәрес” газеталары

**Интернет – ресурслар.**

http://www.ed.gov.ru Белем бирү буенча федераль агентлык
http://www. tatedu.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы
http://www.edu. kzn.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем порталы
http://www.mon.tatar.ru
http://pedsovet.org Бөтенроссия интернет-педкиңәшмәсе
http://www.shoolexpo.ru
http://. belem.ru
http://. Tat. Tatar - inform.ru ТР мәгълүмат агентлыгы
http://. intertat.ru ТР электрон газетасы
http://. xat.ru Татар хат алышу хезмәте
http://. suzlek.ru on- line русча сүзлек
http://. Kitapxane.at.ru татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе
http://. Tatar.com.ru татар теле сүзлекләр һәм үзөйрәткечләр
http://. Tatarca.boom.ru татарча текстлар
http://. selet.ru “Сәләт” яшьләр
http://. Tatarca.boom.ru татарча текстлар
tatartele 2010.ucoz.ru

**Тематик план**

| № | Дәрес темасы | Сәгсаны | Дәрес тибы | Эчтәлек элементлары (төп төшенчәләр) | Эшчәнлек төрләре, үлчәмнәре | Материал үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | Кабатлау. Исем | 1 | ЛГКК | Лексик базаны искә төшерү: калын урман, мул сулы табигать, күпмилләтле, тигез хокуклы, тынычлык, сафлык, сурәтләнгән | Таблицалар белән эш. | Килеш кушымчаларын искә төшерү, текст белән эшләү алымнары |
| **2** | Авазлар. Кабатлау | 1 | ЛГКК | Күмәк эш, калын һәм нечкә сузыклар, сингармонизм законы | Тест, күнегүләр эшләү | Авазларны дөрес әйтү, сүзгә кушымчаларны дөрес ялгау принцибы |
| **3-4** | Кушма җөмлә турында мәгълүмат | 2 | ГКФ<br>ГКК | Баш кисәкләр, грамматик нигез, җөмләләрне аеру | Схемалар белән эш | Гади җөмлә һәм кушма җөмләләрне таба белү |
| **5** | Тезмә кушма җөмләләр | 1 | ГКФ | Кушма җөмлә, тезмә кушма җөмлә, теркәгечләр | Схемалар белән эш | Җөмләдә баш кисәкләрне таба белү, шартлы билгеләр б/н күрсәтү |
| **6** | Тезмә кушма җөмлә төрләре | 1 | ГКФ | Тезүче теркәгечләрне искә төшерү: һәм, ә, ләкин, әмма | таблица | Тезмә кушма җөмләләрне таба белү, практикада куллану |
| **7** | Тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре | 1 | ГКФ | Күнегүләр эшләү, теркәгечләрне аера белү | таблица | Тыныш билгеләрен дөрес кую |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **8** | Мөстәкыйль эш.Тезмә кушма җөмлә. | 1 | Контроль дәрес | Күнегүләр эшләү | | Тыныш билгеләрен дөрес кую, җөмлә чикләрен дөрес билгеләү |
| **9-10** | Иярченле кушма җөмләләр.<br>Иярченле кушма җөмлә төрләре | 1<br><br>1 | ЛГКФ<br><br>ГКК | -Таблицаны күзәтү<br>-рус теле белән чагыштыру<br>Синтетик кушма җөмлә, аналитик иярченле кушма җөмлә | таблица | Баш һәм иярчен җөмләләрне аера белүгә ирешү |
| **11-12** | Иярчен кушма җөмләдә бәйләүче чаралар.<br>Аналитик һәм синтетик чаралар. | 1<br><br>1 | ЛГКФ<br><br>ЛГКФ | -Рус теле белән чагыштыру;<br>-бәйләүче чаралардан җөмлә төрен аера белү | Бәйләүче чараларны язу | Аналитик һәм синтетик бәйләүче чараларны билгели белүгә ирешү |
| **13** | Синтетик иярченле кушма җөмләләр | 1 | ГКФ | Татар телендә генә кулланыла торган җөмлә-ләр; | Күнегүләр эшләү | Синтетик иярченле кушма җөмләләрне таный белү |
| **14** | Синтетик иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре | 1 | ЛГКФ | бәйләүче чаралар: кушымчалар, янәшә тору, бәйлекләр | Күнегүләр эшләү, | Кушма җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес кую |
| **15** | Контроль эш.<br>Грамматик бирем | 1 | Контроль дәрес | Биремнәр эшләү | Үтелгән материал | Баш һәм иярчен җөмләләрне аера белүгә ирешү |
| **16** | Хаталар өстендә эш | 1 | ГКК<br>Д.С. | Күнегүләр эшләү | | Баш һәм иярчен җөмләләрне аера белүгә ирешү |
| **17** | Аналитик иярченле кушма җөмләләр | 1 | ГКФ | Аналитик чаралар: ияртүче теркәгечләр, мөнәсәбәтле сүзләр | Күнегүләр эшләү, сөйләмгә кертү | Аналитик һәм синтетик чараларны аера белү |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **18** | Иярчен ия, иярчен хәбәр җөмләләр | 1 | ГКФ | Иярчен ия, иярчен хәбәр җөмләләр | Кагыйдәне кулланып эшләү | Күнегүләр эшләү, сөйлләмдә куллану |
| **19** | Аналитик иярчен аергыч җөмләләр | 1 | ГКФ Д.С. | Әңгәмә, күнегүләр эшләү, чагыштыру | Күнегү эшләү, | Иярчен аергыч җөмләләрнең аналитик төрләрен билгели белү |
| **20** | Синтетик иярчен аергыч җөмләләр | 1 | ГКФ | Әңгәмә, күнегүләр эшләү, чагыштыру | Кагыйдәне сорау. | Иярчен аергыч җөмләләрнең синтетик төрен билгели белү. |
| **21** | Аналитик иярчен җөмләләрне синтетик төргә әйләндерү | 1 | ГКФ | Синтетик һәм аналитик чараларны дөрес куллану | Күнегү эшләү | Тәрҗемә эше |
| **22** | Иярчен тәмамлык җөмлә(аналитик төре) | 1 | ГКФ | Синтетик һәм аналитик чараларны дөрес кулланырга өйрәнү | Кагыйдәне сорау | Әңгәмә, күнегүләр эшләү, чагыштыру |
| **23** | Иярчен тәмамлык җөмлә(синтетик төре) | 1 | ЛГКК | Синтетик иярчен тәмамлык җөмлә | Күнегүләр | Җөмләләрне дөрес куллану |
| **24** | Хат язу күнекмәәре | 1 | ЛГКК | Башлам, төп өлеш, йомгаклау | Индивидуаль эш. | Алган белемнәрне практикада куллана белүгә ирешү |
| **25** | Мөстәкыйль эш. Хат язу күнекмәәре | 1 | ЛГКК | Сау бул, кадерле, сәлам | Индивидуаль эш. | Алган белемнәрне практикада куллана белүгә ирешү |
| **26** | Тыңлап аңлау күнекмәләре. Музейда. | 1 | ЛКК. | Индивидуаль эш. | Индивидуаль эш. | Текстка якын итеп хатасыз язу һәм логик эзлеклелекне саклау. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **27** | Иярчен хәл җөмләләр. | 1 | | Хәл җөмлә төрләре | Әңгәмә. | Иярчен җөмлә төрләрен аера белү. |
| **28** | Иярчен вакыт җөмлә(аналитик төре) | 1 | ГКФ | Аналитик вакыт җөмлә | Күнегүләр эшләү. | иярчен вакыт җөмләләрнең төрләрен аера белү |
| **29** | Иярчен вакыт җөмлә(синтетик төре) | 1 | ГКФ | Синтетик вакыт җөмлә | Тест | иярчен вакыт җөмләләрнең төрләрен аера белү. |
| **30** | Контроль эш. Иярчен аергыч, тәмамлык, җөмләләр. | 1 | Контроль | Грамматик күнекмәләрне камилләштерү | Язма эш. | Җөмләләрне дөрес төзергә өйрәнү. |
| **31** | Хаталар өстендә эш. Иярчен кушма җөмләләр. | 1 | ЛГКК | Җөмләләрне стиль ягыннан тикшерү, хаталарны кагыйдәләргә нигезләнеп төзәтү | Карточкалар белән эш. | Тотрыклы белем системасына ирешү күнекмәләрен булдыру |
| **32** | Диалогик сөйләмне үстерү | 1 | Д.С. | Үтелгән темаларны диалогик сөйләмдә куллануга ирешү | | Сөйләм культурасына ирешү |
| **33** | Тест биремнәре үтәү | 1 | ГКК | Төрле типтагы җөмләләр белән эш итә белү күнекмәләре булдыру | Карточкалар белән эш. | Әңгәмә. Кабатлау. |
| **34** | Иярчен урын җөмләләр. | 1 | ГКФ | Урын җөмләләр, мөнәсәбәтле сүзләр | Күнегүләр эшләү. | Иярчен урын җөмләләрне аера белү. |
| **35** | Иярчен шарт җөмләләр. | 1 | ГКФ | Әгәр, -са\сә кушымчалары | Күнегү ләр эшләү. | Теоретик белемнәрне гамәли яктан дөрес |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | куллану |
| **36** | Иярчен сәбәп җөмләләр (аналитик төре) | 1 | ЛГКФ | Чөнки, шул сәбәпле сүзләрен актив куллану | күнегү | Аналитик чараларны таба белү. |
| **37** | Иярчен сәбәп җөмләләр (синтетик төре) | 1 | ЛГКФ | Тактада һәм дәфтәрләрдә күнегүләр эшләү. | күнегү | Синтетик чараларны дөрес билгеләү. |
| **38** | Иярчен максат җөмләләр. | 1 | ЛГКФ | Мөнәсәбәтле сүзләр | Карточкалар | Иярчен максат җөмләләрне дөрес билгеләү. |
| **39** | Иярчен хәл җөмләләр. Тест | 1 | ГКК | Индивидуал эш. | Әңгәмә,тест | Не дөрес |
| **40** | Контроль эш. грамматик бирем | 1 | Контроль тикшерү. | Кушымчаларны дөрес куллану, бәйләүче чараларга игътибар итү | | җөмләләр төзү,иярчен җөмләләрне дөрес күрсәтү. |
| **41** | Хаталар өстендә эш. Иярчен җөмләләрне кабатлау. | 1 | ЛГКК | Кагыйдәләргә нигезләнеп, хаталарны төзәтү | карточкалар | Хатаны табарга өйрәнү |
| **42** | Иярчен рәвеш җөмләләр (синтетик төр) | 1 | ЛГГФ | Рус теле белән чагыштыру | Дәреслек белән эш. | Синтетик чараларны аеру |
| **43** | Иярчен рәвеш җөмләләр(аналитик төр) | 1 | ЛГКФ | Бәйләүче чараларны урынлы куллану | Дәреслек белән эш. | Аналитик чараларны аеру. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **44 - 45** | Иярчен кире җөмләләр | 2 | ГКФ<br>ГКК | Тикшерү тәртибенә игътибар | | Рус теле белән чагыштыру. |
| **46** | Кушма җөмләләргә күнегүләр. | 1 | ГКФ | Тәрҗемәсен белеп, аңлап эшләү күнекмәләре | Күмәк эшләү | Иярчен күләм җөмләләрне таба белү. |
| **47** | Грамматик күнекмәләр камил-ү. | 1 | ГКК<br>Д.С. | Җөмләләр өстендә белгәннәрне ныгыту | Мөстәкыйль эшләү | Иярчен җөмлә-ләрне дөрес билгеләү |
| **48**<br><br>**49** | Диалог “Буш вакыт”<br><br>БСҮ.Хикәя төзү ”Татарстан” | 1<br><br>1 | Д.С.<br><br>М.С. | Парлы эш<br><br>Бирелгән темага хикәя төзи белү | | Грамматик конструкцияләрне дөрес кулланып, сөйләм төзү |
| **50** | Тыңлап аңлау күнекмәләре “Спорт” | 1 | ЛКФ | Спорт сарае, шөгыльләнәм, кызыксынам, түгәрәккә йөрим | Мөстәкыйль эш | Җөмләләрне дөрес төзү. |
| **51 - 52** | Катлаулы кушма җөмләләр.<br>Тест биреме үтәү | 1<br><br>1 | ГКФ<br><br>ЛГКК | Тактадагы мисаллар белән эш. | | Катлаулы кушма җөмләләрне аера белү. |
| **53** | Милли сәнгать.Текст өстендә эш | 1 | ЛКФ | Сәнгать, рәссам, сурәтләү, милли музей, рәсем | Җөмлә төзү | Хикәя төзү. |
| **54** | Үтелгән темаларны кабатлау | 1 | ЛГКК | Карточкалар белән эш | | |
| **55** | Тикшерү диктанты. Язгы көннәр | 1 | тикшерү | Орфографияне дөрес куллану | Мөстәкыйль эш | Дөрес язу күнекмәләрен ныгыту |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **56** | Текст эчендәге җөмләләр арасында мөстәкыйль бәйләнеш. | 1 | ЛГКФ | Текстны аңлау, сораулар төзү, эчтәлекне сөйләп карау | Аерым текстлар төзү. | Текст мисалында аңлату. |
| **57** | Текст төзелеше. | 1 | ЛГКК | Текст белән эшләү. | | Сөйләмне дөрес кабул итү. |
| **58** | Бирелгән темага Хат зу | 1 | БСҮ. | План төзү. Сөйләп карау. | | Җөмләләрне дөрес төзү өстендә эш. |
| **59** | Тәрҗемә итү күнегүләре. Рус теленнән татарчага тәрҗемә | 1 | ЛГКФ | тәрҗемә | Күнегүләр эшләү. | Сүзлекләр белән эшли белү |
| **60** | Тәрҗемә итү күнегүләре.татар теленнән русчага тәрҗемә | 1 | ЛГКФ | тәрҗемә | Күнегүләр эшләү. | Сүзлекләр белән эшли белү |
| **61** | Аралашу күнекмәләре | 1 | Д.С. | Аралашу күнек-мәләре.(Төрле ситуациягә) | Телдән күнегүләр эшләү | Итәгатьле сөйләм |
| **62** | Грамматик биремле контроль диктант “Сихәтле ай” | 1 | контроль | Сүзләрне аңлау | Диктант язу | хатасыз язу һәм эзлеклелекне саклау |
| **63** | Хаталар өстендә эш. Кушма җөмләләрне кабатлау | 1 | ЛГКК | Җөмләләрне дөрес итеп төзи белү, дөрес язу күнекмәләрен тикшерү | Мөстәкыйль эш | Үтелгән материалны тормышта куллана белергә |
| **64** | Тыңлап аңлау күнекмәләре | 1 | ЛГКК | Текстка якын итеп хатасыз язу һәм логик эзлеклелекне саклау. | Мөстәкыйль эш | үзбәя |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| **65** | Монологик сөйләм.Туган ягым | 1 | М.С. | Җөмләләрне дөрес итеп төзи белү күнекмәләрен тикшерү | Мөстәкыйль эш | Дөрес сөйләм күнекмәләре |
| **66** | Җәлилчеләр | 1 | ЛГКК | баш киеме, үлгәннәр, танылган, уч төбе, зурайткыч пыяла, тугры дус, бастырып чыгара, көрәштәшләр һәлак булу, кайгыра | | М. Җәлилнең Моабит төрмәсендәге көрәштәшләре турында әңгәмә кора белү |
| **67** | Советлар Союзы герое М. Сыртланова турындагы тексттагы лексик-грамматик материал | 1 | ЛГКФ | Советлар Союзы герое М. Сыртланова турындагы тексттагы лексик-грамматик материалны үзләштерү | | Сүзлекләр белән эшли белү. |
| 68 | Йомгаклау дәресе. | 1 | ЛГКК | Кагыйдәләрне искә төшерү, күнегүләр эшләү | Күнегүләр эшләү | |